**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 27 июль № 544

г. Казань

Муса Җәлил исемендәге республика премиясен бирү турында

Муса Җәлил исемендәге республика премиясен бирү комитеты утырышы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2014 – 2015 еллар конкурсы йомгаклары буенча Муса Җәлил исемендәге республика премиясен түбәндәгеләргә бирергә:

«Идел» яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә – татар яшьләре арасында милли тәрбияне үстерүгә өлеш керткән һәм рухи мирасны пропагандалаган өчен;

югары һөнәри белем бирүче «Казан дәүләт медицина университеты» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фармацевтик химия (аналитик һәм токсикологик химия курслары белән) кафедрасы ассистенты Александра Викторовна Буховецка – фармацевтик химия һәм медицина өлкәсендәге инновацион эшләнмәләре өчен;

композитор Эльмира Җәүдәт кызы Низамовага – «Алтын Казан» мюзиклын иҗат иткән һәм Татарстан Республикасының музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән өчен;

язучы-прозаик Рөстәм Госман улы Галиуллинга – татар әдәбиятын үстерүгә өлеш керткән һәм яшьләр өчен «Юлларда җил ак иде...» («На дорогах белый ветер…»), «Одиночество» китапларын иҗат иткән өчен; шагыйрә Луиза Николаевна Шаровага (Луиза Янсуарга) – яшьләр арасында актив иҗтимагый-агарту эшчәнлеге һәм «Болан кызы» шигырьләр җыентыгын иҗат иткән өчен.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\544.doc